Татарча التترية

# 3 Тәүхиднең төрләре

Бөек Аллаһны Аңа гына хас булган хакимлектә, илаһылыкта һәм исем-сыйфатларында берләү

Тәүхиднең өч төре бар.

### Тәүхид әсмә үә-с-сыйфат

Аллаһны Ул Үзе турында раслаган нәрсәләрне раслап, инкарь иткән нәрсәләрне инкарь итеп, Үз китабында яки Аның илчесе аша хәбәр ителгән исем-сыйфатларында берләү. Бу исем сыйфатларны бер нәрсәгә дә охшатмыйбыз, яки үзгәртеп бозмыйбыз, кире какмыйбыз һәм ничек дип сорау бирмибез.

### Тәүхид әл-улюхиййә

Аллаһны гыйбадәттә ягъни колларының гамәлләрендә берләү.

### Тәүхид әр-рубубийә (хакимлек)

Ул - бөек Аллаһны Аның гамәлләрендә яки барлыкка китерүдә, хакимлектә һәм идарә итүдә берләү.

# Диннең өч дәрәҗәсе бар.

### Ихсән

Ихсән ул – Аллаһны күргән кебек гыйбадәт кылу, һәм әгәр син Аны күрмәсәң Ул сине күрә икәнен белеп тору.

**Бер багананың ике дәрәҗәсе:**

1. Күрү гыйбадәте – ул Аллаһка Аны күргән шикелле гыйбадәт кылу
2. Өстеңнән күзәтү гыйбадәте – син Аллаһны күрмәсәң, Ул сине күреп торганын белеп гыйбадәт кылу.

### Иман

Иман – ул тел белән әйтү, йөрәк белән инану һәм тән әгъзалары белән гамәл кылу. Иман арта һәм кими.

**Иманның баганалары алты:**

1. Аллаһка ышану
2. Аның фәрештәләренә ышану
3. Аның китапларына ышану
4. Аның илчеләренә ышану
5. Кыямәт көненә ышану
6. Тәкъдиргә ышану

### Ислам

Ислам – ул Аллаһка тәүхид аша буйсыну, буйсынучылык аша Аңа ияреү һәм ширектән һәм аның әһелләреннән баш тарту.

**Исламның 5 баганасы:**

1. Ике шаһәдәтнамә
2. Намаз
3. Зәкят
4. Ураза
5. Хаҗ кылырга мөмкинлек булса хаҗ кылу

# 4 Тыелган нәрсәләрнең төрләре:

### Кече гөнаһлар

Олы гөнаһлардан кала башка гөнаһлар

Олы гөнаһлар тәүбә аша юкка чыга, кече гөнаһларны гел кылу олы гөнаһларга китерә.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Гөнаһларга салкын караш белән карамагыз, чынлыкта, алар кешедә аны һәлак иткәнчегә кадәр җыелып барачак".

### Олы гөнаһлар

Хас җәза бирелгән барлык гөнаһ Сихер, ата-анага буйсынмау, риба, зина кылу, ир-атларның бер-берсе белән җенси мөнәсәбәткә керү, алдау, исерткеч эчемлекләр эчү, урлау, гайбәт сату, бер хаксызга кешене үтерү, ятимнәр малын ашау.

### Кече ширек

Ислам диненнән чыгармый, олы гөнаһларның иң зурысы. Аллаһ теләде һәм син дигән сүзләр, Аллаһтан башкалар белән ант итү, ширек амулетлары, начар билгеләргә ышану һәм күрәзәчелек, хиромантия һәм саклау сәбәбе дип яки күз тидерүдән саклый дип ышанып төрле бөтиләр элү.

### Олы ширек

Ислам диненнән чыгаручы, һәм әгәр тәүбә итмичә үлеп китсә, гафу ителмәячәк.

Аллаһка тиңдәш китерү, ягъни Аңа дога белән ялварган төсле башкаларга ялвару, яки курку, яки өмет итү, яки Аллаһны яраткан кебек калганнарны ярату, я инде нинди дә булса гыйбадәтне Аллаһтан кала башкаларга багышлау.